ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ һӘМ АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮНЕ,
ӘЙЛӘНЕШТӘ ЙӨРТҮНЕ,
СЫЙФАТЫН ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРҮЕН
ТӘЭМИН ИТҮ һӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

# ПРИКАЗ

31.01.2019 № 10-07/23

Казан ш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә биләнеше коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

"Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының "Керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының "Аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701

номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында" 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә биләнеше коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлегенә әлеге боерыкны Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә, шулай ук "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы күздә тоткан чикләмәләр, йөкләмәләр һәм җаваплылык турында аңлатырга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлүен тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең "Вазыйфалар исемлеген раслау турында" 2016 елның 26 августындагы 12-07/74 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Җитәкче** **Ж.Й.Әхмәтханов**

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь инспекциясенең
2019 елның "31" 01 № 10-07/23
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә биләнеше коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. "Җитәкчеләр" категориясендәге вазыйфалар:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары;

территориаль орган башлыгы;

территориаль орган башлыгы урынбасары;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе аппараты бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе аппараты бүлеге башлыгы урынбасары;

территориаль орган бүлеге башлыгы.

2. "Белгечләр" категориясендәге вазыйфалар:

2.1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе аппаратында:

контроль-инспекция бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

халык куллана торган товарларның сыйфатын тикшерүдә тоту бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

административ һәм суд практикасы бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

ваклап сатуга килә торган алкоголь продукциясен тикшерүдә тоту бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

контроль-инспекция бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

административ һәм суд практикасы бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

ваклап сатуга килә торган алкоголь продукциясен тикшерүдә тоту бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты.

2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнарында:

консультант (лицензияләү буенча);

консультант (хокукый мәсьәләләр буенча);

әйдәп баручы белгеч-эксперт (хокукый мәсьәләләр буенча);

контроль-инспекция бүлеге консультанты;

эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге консультанты;

алкоголь продукциясе кертүне тикшерүдә тоту бүлеге консультанты;

контроль-инспекция бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты;

эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты;

алкоголь продукциясе кертүне тикшерүдә тоту бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты;

контроль-инспекция бүлеге белгеч-эксперты;

эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге белгеч-эксперты;

алкоголь продукциясе кертүне тикшерүдә тоту бүлеге белгеч-эксперты.

3. "Тәэмин итүче белгечләр" категориясендәге вазыйфалар:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең әйдәп баручы белгече;

дәүләткә сатып алулар һәм эшчәнлекне тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече;

халык куллана торган товарларның сыйфатын тикшерүдә тоту бүлегенең әйдәп баручы белгече;

административ һәм суд практикасы бүлегенең әйдәп баручы белгече;

оператив муниципальара контроль бүлегенең әйдәп баручы белгече;

халык куллана торган товарларның сыйфатын тикшерүдә тоту бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

территориаль органның контроль-инспекция бүлегенең 2 разрядлы өлкән белгече;

территориаль органның эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенең 2 разрядлы өлкән белгече;

территориаль органның алкоголь продукциясе кертүне тикшерүдә тоту бүлегенең 3 разрядлы өлкән белгече;

территориаль органның эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенең 3 разрядлы өлкән белгече;

территориаль органның контроль-инспекция бүлегенең 1 разрядлы белгече;

территориаль органның алкоголь продукциясе кертүне тикшерүдә тоту бүлегенең 1 разрядлы белгече;

территориаль органның эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлегенең 1 разрядлы белгече.